| СОВЕТ<br>НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Нижнее Чекурское

2020 нче елның 02 июне № 61/4

**Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында Карар**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының түбәндәге вәкаләтләрен Түбән Чәке авыл җирлеге советына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлекләрне шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге советына тапшыра:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм карау өчен тәкъдим итү.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Түбән Чәке авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Түбән Чәке
авыл җирлеге башлыгы: О.Б.Албутов